ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» февраль 2020 ел № 37

**Әгерҗе муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүгә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлеге буенча дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча муниципаль хокукый актларны гамәлдән чыгару турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү Инспекциясенең 2019 елның 2 декабрендәге 09-08/6284 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Олешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча административ регламентны раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 81 номерлы карарына Татарстан Республикасы Прокуратурасының 2020елның 28 гыйнварындагы 02-08-01/65 номерлы протестын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлдән чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Өлешләп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча административ регламентны раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 81 номерлы карары;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле

төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 3 апрелендәге 127 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча җаваплы органны билгеләү турында» 2019 елның 14 мартындагы 89 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенец өлешләп төзү өлкәсендә контроль (күзәтчелек) вәкаләтләрен үтәү буенча белгечнең вазифа инструкциясен раслау турында» 2019 елның 8 февралендәге 43 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2021 елларга Әгерҗе муниципаль районында күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 70 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Әгерҗе муниципаль районының Капиталь төзелеш идарәсе муниципаль учреждениесен Әгерҗе муниципаль районында күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләү турында» 2008 елның 22 апреленнән 171 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресф буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. И. Шәмсетдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**